| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районынын Иске Имән авыл жирлеге** |

---

| | |
|---|---|
| **КАРАР**<br>**23.12.2024 ел** | **КАРАР**<br>**№ 21** |

Белешмә (өземтә) бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү
административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтхне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 нче номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга;

2.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2021 елның 24 июнендәге 9 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Ә.Исламова